**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 18 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН СОВЕТ ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГ**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Новая
дом 18. Тел.(885552) 3-44-45.

E-mail Diliya.Mirzaeva@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«06» июнь 2024 ел** **№ 9**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз
булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Физик затларның җирле салымнары суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Югары Яхшыйавыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Әхәтов И. Х.